ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 ел « 3 » июля** **№ 470**

**Арча районы башкарма комитетының 2018 елның 31 августында чыккан «Арча муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында "гы 732 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августында чыккан «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы 665 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21 июнендә чыккан «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы карамагындагы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары һәм аерым типтагы башка оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында" 505 нче номерлы карар нигезендә Арча районы башкарма комитеты Карар бирә:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 31 августында чыккан «Арча муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы 732 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

V кисәктә:

2.4 өлешенең 6 нчы абзацында “26,5” цифрын “41,0” белән алыштырырга;

6 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6 нчы таблица

Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процентлар |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче хезмәткәрләр һөнәри квалификация төркеме | - | 41,0 |
| Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче хезмәткәрләр һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Педагог хезмәткәрләр һөнәри иквалификация төркеме | беренче-дүртенче | 41,0 |
| Структур бүлекчә җитәкчеләре һөнәри квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0»; |

4.4 өлешенең 6 нчы абзацында “26,5” цифрын “41,0” белән алыштырырга;

11нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6 нчы таблица

Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процентлар |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче хезмәткәрләр һөнәри квалификация төркеме | - | 41,0 |
| Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче хезмәткәрләр һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Педагог хезмәткәрләр һөнәри иквалификация төркеме | беренче-дүртенче | 41,0 |
| Структур бүлекчә җитәкчеләре һөнәри квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0»; |

4.4 өлешенең 6 нчы абзацында “26,5” цифрын “41,0” белән алыштырырга;

11нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

11 нче таблица

Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Вазыйфалар исеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| “Техник башкаручылар һәм өстәмә составтагы артислар” һөнәри квалификация төркеме | Барлык вазыйфалар | 41,0 |
| “Кинематография, мәдәният һәм сәнгатьнең урта звено езмәткәрләре” һөнәри квалификация төркеме | аккомпаниатор, костюмнар бүлмәсе мөдире | 49,0 |
| | Түгәрәкләр, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксынучанлык буенча клублар җитәкчесе, культура чараларын оештыручы | 61,0 |
| “Кинематография, мәдәният һәм сәнгатьнең әйдәп баручы звено хезмәткәрләре” һөнәри квалификация төркеме | Барлык вазыйфалар | 49,0 |
| “Кинематография, мәдәният һәм сәнгатьнең җитәкче хезмәткәрләре” һөнәри квалификация төркеме» | Барлык вазыйфалар | 49,0»; |

VIII кисәкнең 8 нче өлешендәге бишенче абзацта «10» цифрын «20» цифрына алыштырырга.

2.Әлеге Карар 2019 нчы елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту үземнең өстә кала.

Башкарма комитет җитәкчесе И.А.Галимуллин